# Туган телем

Иң кадерле туган телем - татар телем!

Тәүге тапкыр аваз салган ана телем.

Күкрәк сөте аша иңгән татлы телем!

Зур җиһанга яңгыраган бөек телем!

Күгебездә йолдыз кебек балкыр телем,

Сабыйлыкта бишек көен тыңлар телем.

Яшьлек бусагасын атлап уздым туган телдә,

Уй-фикерем югалмасын киләчәктә.

Туган телдә теләк телим, рәхмәт укыйм.

Матур көйгә җырлар җырлап, шигырь юллыйм.

Канлыбызга сеңеп, сакланып кал, бөек телем!

Һәр татарга кирәк булган газиз телем!

*Раилә Гирфанова, 2025 ел*